ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 04 » 03 2026 ел № 232

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 04.06.2025 ел, № 585 карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 13.07.2015 ел, № 220-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 04.06.2025 ел, № 585 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга кушымтаны, әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

В.А.Андреева
8(85593)2-42-07

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
04.03.2026 ел № 232

# Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестры

| Теркәлү номеры | Маршрут номеры | Маршрут исеме | Арадаш тукталыш пунктлары исеме яисә җирлекләр исеме | Тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күз алдында тотыла торган урамнар, автомобиль юллары атамасы | Озынлыгы (бер якка), км | Транспорт чараларының төре | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен кулланыла торган транспорт | | Транспорт чараларының экологик характеристикалары | | | | Ташуларны гамәлгә ашыра башлау датасы | Ташучының исеме | Ташучының урнашкан урыны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | сан | класс | 2 | 3 | 4 | 5 | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 1 | 104 | Урыссу-Каразирек | Урыссу штб - Каклы Күл авылы - Подгорный авылы - Бәйрәкәтамак авылы - Көрәш Бүләк авылы – Иске Каразирек авылы - Яңа Каразирек авылы | Урыссу штб автовокзалы - Урыссу штб, Үзәк тыкрык - Урыссу тимер юл вокзалы - Урыссу, Яңарыш паркы - Каклы Күл авылы, Елга урамы - Подгорный бистәсе, Үзәк ур. - Бәйрәкәтамак ав. - Көрәш Бүләк ав. - Иске Каразирек ав. - Яңа Каразирек ав. | 55 | автобус | 1 | кече | | | + | | 1966 | ИП Идрисов Л.И. | РФ, ТР, Ютазы районы, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 1А й. |
| 2 | 103 | Урыссу-Кәрәкәшле | Урыссу штб – Әбсәләм авылы – Тарлау авылы - Ак-Юл авылы – Ютазы авылы - Салкын Чишмә авылы - Ак-Чишмә авылы борылышы – Кәрәкәшле авылы - Урал б. - Алма-Ата авылы | Урыссу автовокзалы - Октябрьский шәһәре (КПМ) борылышы - Әбсәләм авылы - Тарлау авылы борылышы - Ак Юл - Ютазы ав. - Ык авылы - Салкын Чишмә ав. борылышы - Ак Чишмә авылы борылышы - Кәрәкәшле ав., Көчле Елга ур. - М. Зәкиев ур. - Урал бистәсе - Алма-Ата Яшел ур. | 42 | автобус | 1 | кече | | | + | | 1966 | ИП Идрисов Л.И. | РФ, ТР, Ютазы районы, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 1А й. |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | 102 | Урыссу-Бәйрәкә | Урыссу штб - Иске Урыссу авылы борылышы - Иске Урыссу авылы - Кече Урыссу авылына керү - Ташкичү авылы - Хөррият авылы - Бәйрәкә авылы | Урыссу штб автовокзалы - Урыссу штб, Үзәк тыкрык - Урыссу тимер юл вокзалы - Урыссу штб, Ютазы тыкрыгы (АТП) - Иске Урыссу авылы, Совет урамы - Кече Урыссу авылы, Совет урамы - Ташкичү авылы, Чишмә урамы - Хөррият авылы, Хөррият ур. - Бәйрәкә авылы, Ютазы ур. | 31 | автобус | 1 | кече | | | + | | 1966 | ИП Идрисов Л.И. | РФ, ТР, Ютазы районы, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 1А й. |